| | |
|---|---|
| СОВЕТ ИСЕРГАПОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСЕРГЭП АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
| РЕШЕНИЕ | КАРАР |

24 мая 2024 года Исергэп авылы №104

Вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында
Баулы муниципаль районы "Исергәп авыл җирлеге"
муниципаль берәмлегенең җирле әһәмияттәге аерым
мәсьәләләрен хәл итү буенча

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясының 4 өлешенә, Исергапов авыл җирлеге Уставына ярашлы рәвештә, Исергапов авыл җирлеге Советы:

1. Баулы муниципаль районы Советына Баулы муниципаль районы Башкарма комитетына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча Баулы муниципаль районы Исергәп авыл җирлеге Башкарма комитетының түбәндәге вәкаләтләрен тапшыру турындагы мәсьәләне карарга тәкъдим итәргә:

җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт булдыру һәм аның эшчәнлеге тәртибен раслау;

гарантияләнгән җирләү хезмәтләре исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен билгеләү.

2. Баулы муниципаль районы Советы әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән тәкъдимне Баулы муниципаль районы Исергәп авыл җирлеге башкарма комитетына кабул иткән очракта:килешү төзергә

әлеге карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатларында Баулы муниципаль районы Исергәп авыл җирлеге Советының 2024 елга һәм 2025 һәм 2026 еллар план чорына Исергәп авыл җирлеге бюджеты турындагы карарына үзгәрешләр кертү турындагы карары проектын эшләү һәм бюджет законнары нигезендә карауга тапшыру.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында.

4. Әлеге карар рәсми рәвештә игълан ителгән көннән үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Башлык, Совет Рәисе
Исергәп авыл җирлеге                                                  А. А. Аглиуллин